ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

17.08.2022 г. Казань № 127-3/э-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 №535-19/э-2020 карары белән «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 №637-29/э-2021 карарын гамәлдән чыккан дип тану турында

Татарстан Республикасы Югары Судының 2022 елның 11 мартындагы 3а-245/2022 номерлы карарын, Гомуми юрисдикциядәге дүртенче апелляция судының № 66а-1381/2022 эш буенча 2022 елның 13 июлендәге билгеләмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 17 августындагы 22-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә аерым тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 № 535-19/э-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 №637-29/э-2021 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 № 637-29/э-2021 карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 16.12.2021 № 637-29/э-2021 карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 535-19/э-2020
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.08.2022 № 127-3/э-2022
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы территориясендә «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр индивидуаль тарифлар

| т/с | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1. | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2021 | 122 318,84 | 80,81 | 0,36354 | 122 318,84 | 80,81 | 0,36354 |
| | | 2022 | 141 255,32 | 85,60 | 0,51388 | 141 255,32 | 85,60 | 0,51388 |
| | | 2023 | 125 157,00 | 80,81 | 0,37010 | 125 157,00 | 80,81 | 0,37010 |
| | | 2024 | 125 637,73 | 80,81 | 0,37121 | 125 637,73 | 80,81 | 0,37121 |
| | | 2025 | 126 122,68 | 80,81 | 0,37233 | 126 122,68 | 80,81 | 0,37233 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 № 535-19/э-2020 карарына 3 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.08.2022 № 127-3/э-2022 карары редакциясендә)

«Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2021-2025 елларга кирәкле тулай кереме
(югалтуларны исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2021 | 121 330,50 |
| | | 2022 | 73 091,15 |
| | | 2023 | 124 145,74 |
| | | 2024 | 124 622,57 |
| | | 2025 | 125 103,61 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге